**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 22-3 «14» декабрь 2020 ел

2018 елның 13 декабрендәге 224-32 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне юкка чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» ( 12.12.2019 №302-41 карар редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне юкка чыгару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең 2020 елның 11 июлендәге 1036 номерлы "Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контрольдә тоту чараларын үткәргәндә үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" карарының 1 нчекушымтасының 10 пунктын исәпкә алып,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. 2018 елның 13 декабрендәге 224-32 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне юкка чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» (12.12.2019 №302-41 карар редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы милкендәге муниципаль мөлкәтне юкка чыгару тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3.2.4 пунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төп чараларны техник яктан катлаулы җиһазларга керткәндә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Техник яктан катлаулы товарлар исемлеген раслау турында " 2011 елның 10 ноябрендәге 924 номерлы карары нигезендә, техник яктан катлаулы товарлар исемлегенә таянып эш итәргә киңәш ителә»;

- 4.4 пунктының дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- төп чараларны техник яктан катлаулы җиһазларга керткәндә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Техник яктан катлаулы товарлар исемлеген раслау турында»2011 елның 10 ноябрендәге 924 номерлы карары нигезендә, техник яктан катлаулы товарлар исемлегенә таянып эш итәргә киңәш ителә.».

2. Әлеге карарның 3.2.4. һәм 4.4. пунктлары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә :http://aznakayevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин